| | |
| --- | --- |
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>Совет Аграмаковского сельского поселения<br>Спасского<br>муниципального района<br>422859, с. Аграмаковка,<br>ул. Школьная, дом 2, тел. 8-84347 36834 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>Спас муниципаль районы<br>Аграмак авыл җирлеге Советы<br>422859 Аграмак авылы, Мәктәп ур. 2 йорт<br>тел. 8-84347 36834 |

ОГРН 1021605754147, ОКПО 93066204, ОКАТО 92232805000,
ИНН/ КПП 1637000057/163701001, ОКТМО 92632405

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

# КАРАРЫ

№1 15 ноябрь 2019 ел.

## Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге Уставының 22 нче статьясы нигезендә, Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

Карары:

1. 2019 елның 25 ноябренә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Аграмак авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. 2019 елның 26 ноябренә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Татар Такталы авылында, Аграмак авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Спас муниципаль районының Аграмак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, (көндезге формада укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш) 200 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаны түбәндәге түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

- Аграмак һәм Татар Такталы авылларында урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү);

- Аграмак һәм Татар Такталы авылларында юлларны кардан чистарту
(МТЗ-82 тракторына ягулык сатып алу ,килешү буенча эш өчен түләү);

- янгын сүндерү машинасын ремонтлау (янгын сүндерү машинасы өчен з/частьләр сатып алу).

- Аграмак һәм Татар Такталы авылларында чүплекләрне буртлау (ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

- түбәндәге бәйрәмнәрне оештыру һәм үткәрү: Аграмак авылында Авыл көне, Татар Такталы авылында Сабантуй, « Халыкара өлкәннәр көне» , Бөек Җиңүнең 75 еллыгы, Яңа ел, ТАССРның 100 еллыгы, (бүләкләр, сувенирлар сатып алу);

- Татар Такталы авылында артезиан скважинасы өчен насос сатып алу.

« ӘЙЕ» « ЮК »

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларына һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Спас
муниципаль районы
Аграмак авыл җирлеге
башлыгы: Р. Т. Галәветдинова

СОВЕТ АГРАМАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ